БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 11 2020 ел №223

2021 елга торак урыннан файдаланган өчен түләү (наемга алган өчен түләү) күләмен, муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларда торак урын милекчеләре өчен торак урыннарын карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Балтач район Советының «Балтач муниципаль районы коммуналь комплексы оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифларны җайга салу тәртибе турында» 2007 елның 19 ноябрендәге 91 номерлы карары нигезендә һәм Балтач муниципаль районы һәм Балтач муниципаль районы җирлекләре арасында төзелгән килешүләр нигезендә, Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе карар бирә:

1. 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр:

- күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен торак урыннарның милекчеләре өчен түләү күләмен, муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларда торак урын милекчеләре өчен торак урыннарын карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләмен; муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наемга алган өчен түләү) күләмен 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Кушымта

## Торак хезмәтләренә тарифлар

| Муниципаль район/ муниципаль берәмлек исеме | Найм | Торак фонды белән идарә итү | Гомуми файдалану-дагы йорт эчендәге урыннарны жыештыру | Йорт яны территория-сен жыештыру | Чүп үткәргечләргә хезмәт күрсәтү | Торак бинага ремонт һәм территорияне төзекләнде-рү | Сууткәргеч-канализа-ция челтәрләре-нә агымдагы ремонт | Үзәк жылылык челтәрләре-нә агымдагы ремонт | Газ белән тәэмин итү челтәрләренә агымда-гы ремонт | Электр белән тәэмин итү челтәрләренә агымда-гы ремонт | Дера-тизация | Йорт эчендәге жилләтү каналларына һәм төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тариф, сум/кв.м | тариф, сум/кв.м. | тариф, су/кв.м. | тариф, сум/кв.м. | тариф, сум/кв.м. | тариф, сум/кв.м. | тариф, сум/кв.м. | тариф, сум/кв.м. | тариф, сум/кв.м. | тариф, сум/кв.м. | тариф, сум/кв.м | тариф, сум/кв.м. |
| | **2021 елның 1 гыйнварыннан** | | | | | | | | | | | |
| Балтач ШЖ | Исәп-хисап методикасы нигезендә | 3,53 | - | 2,80 | - | 2,60 | 2,47 | 1,28 | 0,32 | 0,95 | - | 1,48 |
| Норма АЖ | Исәп-хисап методикасы нигезендә | 3,53 | - | 2,80 | - | 2,60 | 2,47 | - | 0,32 | 0,95 | - | 1,48 |
| Карадуган АЖ | Исәп-хисап методикасы нигезендә | 3,53 | - | - | - | 2,60 | 2,47 | - | 0,32 | 0,95 | - | 1,48 |
| Кече Лызи АЖ | Исәп-хисап методикасы нигезендә | 3,53 | - | - | - | 2,60 | 2,47 | - | 0,32 | 0,95 | - | 1,48 |
| Чепья АЖ | Исәп-хисап методикасы нигезендә | 3,53 | - | - | - | 2,60 | 2,47 | - | 0,32 | 0,95 | - | 1,48 |

| | 2021 елның 1 июленнән | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Балтач ШҖ | Исәп-хисап методикасы нигезендә | 3,68 | - | 2,90 | - | 2,60 | 2,54 | 1,28 | 0,32 | 0,95 | - | 1,48 |
| Норма АҖ | Исәп-хисап методикасы нигезендә | 3,68 | - | 2,90 | - | 2,60 | 2,54 | - | 0,32 | 0,95 | - | 1,48 |
| Карадуган АҖ | Исәп-хисап методикасы нигезендә | 3,68 | - | - | - | 2,60 | 2,54 | - | 0,32 | 0,95 | - | 1,48 |
| Кече Лызи АҖ | Исәп-хисап методикасы нигезендә | 3,68 | - | - | - | 2,60 | 2,54 | - | 0,32 | 0,95 | - | 1,48 |
| Чепья АҖ | Исәп-хисап методикасы нигезендә | 3,68 | - | - | - | 2,60 | 2,54 | - | 0,32 | 0,95 | - | 1,48 |